**Татарстан Республикасы**
**Нурлат  муниципаль районы**
**Киекле  авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

08 май 2026 ел № 21

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2023 елның 01 ноябрендәге 84 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын билгеләү тәртибен салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып билгеләү тәртибен билгеләү турында» 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Киекле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Киекле авыл җирлеге советы КА**РАР ИТТЕ:**

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2023 елның 1 ноябрендәге 84 номерлы Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Киекле авыл җирлеге советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 4 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«4) 2 процент күләмендә түбәндәгеләргә карата билгеләргә:

- Салым салу объектларыннан, кадастр бәясе, проектлана торган күпфатирлы йорт булган, тәгәлләнмәгән төзелеш объектларыннан тыш, һәркайсының 300 миллион сумнан артып киткәндә;»

2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Нурлат  муниципаль районы
Киекле авыл җирлеге Советы рәисе Л.И. Кашапова